17. Isənbət, N. (1917). *Tugan il: (shigyr')* [My Native Land (A Poem)]. Balalar dөn'yasy. No. 1 (mart), 1 p. (In Tatar)

18. Mart'yanova, I. (2002). *Kinovek russkogo teksta: paradoks literaturnoi kinematografichnosti* [Russian Text Cinema Span: The Paradox of Literary Cinematography]. 236 p. St. Petersburg. (In Russian)

19. *Tukai dөn'yasy: izhat* [Tukay's World: A Mystery]. URL: http://gabdullatukay.ru/ (accessed: 02.02.2024). (In Tatar)

20. Dzhalil', M. (2006). *Volshebnyi klubok* [The Magic Ball]. Khabutdinova M. M. Navstrechu bessmertiyu... [K stoletiyu so dnya rozhdeniya tatarskogo poehta-antifashista Musy Dzhalilya]. Pp. 41–42. N. Novgorod, izd. dom "Medina". (In Russian)

21. Dərdemənd (1999). *Agargan kyl* [Grey Hair]. 112 p. Kazan, Məgarif. (In Tatar)

22. Gallyamova, A. G. (2019). *"'Rasprava' nad Zolotoi Ordoi" v seredine XX v.* ["'Reprisals' against The Golden Horde" in the middle of the 20th Century]. Ideologicheskii diskurs v tatarskoi medievistike v svete avgustovskogo Postanovleniya 1944 g. Zolotoordynskoe obozrenie. T. 7, No. 4, pp. 784–797. DOI: 10.22378/2313-6197.2019-7-4.784-797. (In Russian)

23. Gallyamova, A. G. (2015). *Ideologiya i kul'tura* [Ideology and Culture]. Tatarskaya ASSR v period poststalinizma. Pp. 325–445. Kazan'. (In Russian).

24. Khabutdinova, M. M. (2025) *U sovesti variantov net (T.Minnullin): [fil`m Karaurman]* ["Conscience has no options" (T. Minnullin): [film "Karaurman"]] // Zvezda Povolzh`ya. №33(1235). 13-19 sentyabrya. Pp.. 1–2.

---

# ӘЛМӘТ ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ МУСА ҖӘЛИЛ ОБРАЗЫ

**Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы Хәбетдинова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
mileuscha@mail.ru

**Әлфия Рухулла кызы Мотыйгуллина,**
Казан дәүләт мәдәният институты,
Россия, 420059, Казан ш., Оренбург тракты, 3 нче йорт,
alfiya311065@mail.ru

Әлеге мәкаләдә Әлмәт драма театрында куелган «Кайда минем илем?» һәм «Алтынчәч. Мирас» спектакльләрендә Муса Җәлил образы анализлана. Беренчесе документаль спектакль булса, икенчесе – Н. Җиһанов һәм М. Җәлилнең танылган операсына артхаус драма-ремейк булып тора. «Кайда минем илем?» әсәрендә шагыйрь-герой образы легионер, француз каршы тору хәрәкәте легионеры Г. Фәхретдинов хатирәләренә нигезләнә. Бу эпизодик персонаж спектакльдә шагыйрьнең яшерен оешмасында торучы, татар интеллигенциясенең якты вәкиле буларак ачыла. М. Абдукатинов спектаклендә Муса Җәлил драманың төп каһарманы буларак сурәтләнә. Сәхнәләштерелгән әсәрнең төп концепциясе, бер яктан, Шагыйрь турындагы ил мәдәниятендә расланган миф матрицасына тулысынча тәңгәл килә, икенче яктан, иҗат итүчеләрнең ныгып урнашкан кануннардан читләшүен чагылдыра.

**Төп төшенчәләр:** татар әдәбияты, татар театры, Муса Җәлил, шагыйрь турындагы миф, Ильяс Гәрәев, Мурат Абдукатинов

**Сылтама өчен:** Хәбетдинова М. М., Мотыйгуллина А. Р. Әлмәт театры сәхнәсендә Муса Җәлил образы // Tatarica. 2025. № 2 (25). 110–127 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-110-127

## Кереш

Муса Җәлил турындагы әдәбият күптән әдәбият белеменең шактый киң өлкәсен тәшкил итә (В. Воздвиженский, Г. Кашшаф, Ә. Мәхмүдов, Р. Мостафин, Н. Юзиев һ.б. ) [1]. Муса Җәлил – шагыйрь, Муса Җәлил – шәхес, һәр укучының үз Җәлиле бар.

Н. Җиһановның «Җәлил» опера-поэмасы (1956, либретто авторы Ә. Фәйзи), А. Монасыйповның «Муса Җәлил» симфоник поэмасы (1971), А. Лупповның Г. Кутуй шигыренә «Соңгы төн» вокаль-симфоник поэмасы (1965), Р. Еникеевның «Җәлил истәлегенә» вокаль-симфоник поэмасы (1981), Г. Камал исемендәге ТДАТгы спектакльләр («Муса Җәлил», 1957, авт. Н. Исәнбәт, реж. П. Исәнбәт; «Моңлы бер җыр», 1981, авт. Т. Миңнуллин, реж. М. Сәлимҗанов) татар мәдәнияте тарихында үрнәк әсәрләр булып саналалар.

Шунысы куанычлы: бу каһарманлык темасын сәнгатьчә эшкәртү эшенә яшь көчләр алынды. Соңгы унъеллыкта Татарстан Республикасында Муса Җәлилгә һәм Кормаш-Җәлил төркеменең батырлыгын яктыртуга багышланган берничә спектакль барлыкка килде. Алар арасында «Җәлилчеләр истәлегенә» перформансы (2018, авт. Йолдыз Миңнуллина, Луиза Янсуар, реж. Лилия Әхмәтова) [2]; «Кайда минем илем?» (авт. Гарәф Фәхретдинов, реж. Ильяс Гәрәев, Әлмәт дәүләт драма театры) [3]; «Муса. Моабит» триптихы (2021, реж. Алексей Шитиков, Г. Кариев исемендәге Яшь тамашачылар театры) [4]; «Муса. Моабит» театраль дәресе (2023, реж. Булат Гатауллин, Г. Кариев исемендәге Яшь тамашачылар театры); «Алтынчәч. Мирас» (2023, авт. Муса Җәлил, Илгиз Зәйниев, реж. Мурат Абдукатинов, Әлмәт татар дәүләт драма театры); «Җәлил» студентлар мюзиклы (2025, реж. Руслан Фәтхетдинов, КФУ); «Җәлил» операсы (2025, Ә. Фәйзи либреттосы, Нәҗип Җиһанов муз. реж.-куючы Руслан Кәбирҗанов, Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе) [5]. Соңгы елларда бу темага татар кинематографистлары да мөрәҗәгать итте: «Война непрощенных» документаль фильмы (2015, реж. Денис Красильников), «Солдатская шапка» кыска метражлы фильмы (2020, реж. Павел Москвин), «Высокий дух» документаль-спиритик драмасы (2022, авт. Валерия Оразова, реж. Дидар Оразов), «Кара урман» фильмы (2024, реж. Радик Кодаяров). Бу мисаллар Татарстанда бөек татар шагыйренең исемен киң җәмәгатьчелеккә тарату, популярлаштыру өчен планлы рәвештә эш алып барылганлыгын күрсәтә торган дәлилләр булып тора.

## Тикшеренү методлары һәм маетриаллар

Тикшеренү эшенең материаллары итеп Әлмәт театрының «Кайда минем илем?» (авт. Гарәф Фәхретдинов, реж. Ильяс Гареев) һәм «Алтынчәч. Мирас» (2023, авт. Муса Җәлил, Илгиз Зәйниев, реж. Мурат Абдукатинов) спектакльләре алынды. Анализ предметы булып Муса Җәлил образы торды. Тикшеренү тасвирлау һәм чагыштырма ысуллар ярдәмендә алып барылды.

## Фикер алышу

2020 елда Әлмәт дәүләт театры «Кайда минем илем?» спектаклен сәхнәләштерә. Аның нигезенә «Идел-Урал» легионеры ТР Әлмәт районы Карабаш бистәсе кешесе Гарәф Фәхретдиновның истәлекләре, шулай ук легион агитбригадасы тарафыннан башкарылган «Ак каен», «Яшь егетләр, яшь кызлар», «Күбәләгем», «Баламишкин» җырларының архивта сакланган язмалары салынган.

«Идел-Урал» легионы составындагы яшерен оешма эшчәнлеге турында шактый күп язылган (И. Гыйләҗев [6], И. Зәбиров [7], Р. Мостафин [8], А. Әхмәтҗанов [9] һ.б.) Бу тема белән кызыксыну үзгәртеп кору һәм сүз иреге елларында тагын да көчәеп китте. Легионер, Француз каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашкан Гарәф Фәхретдиновның юлы хаксыз рәвештә бик озын була. Аның гаепсез икәнлеген раслаган документлар булса да [10], ул 1989 елда гына реабилитацияләнә. Аяз Гыйләҗев әлеге «ярлыканмаган» кеше истәлеген үзенең «Яра» повестенда (1984, 1988) мәңгеләштерергә җөрьәт итә [11, б. 17–115]. Г. Фәхретдиновның «Кайда минем илем?» дигән хатирәләре 1994 елда гына «Казан утлары» журналында дөнья күрә [12].

Бүгенге көндә шунысы мәгълүм: Кормаш-Җәлил антифашистик төркеменең максаты «Идел-Урал» легионын эчтән таркату», «күтәрелешкә әзерләү» була. Тарихчы И. А. Гыйләҗев билгеләп үткәнчә, «алар

максатларына ирешү өчен 1942 елның көзеннән башлап Германиянең Көнчыгыш министрлыгы тарафыннан махсус легионерлар өчен чыгарыла торган «Идел-Урал» газетасы типографиясен файдалана». «Гайнан Кормашев яшерен оешманың бишлекләре эшен оештырган һәм күзәтеп торган. Германия һәм Польша җирлегендә ирекле йөрү хокукына ия булган Муса Җәлил легионерлар арасында агитация эшен алып барган. “Винета” радиостанциясендә пропаганда эшен Әхмәт Симаев оештырган: ул мәгълүматлар җыйган һәм каршылык төркеме өчен листовкалар әзерләгән. Листовкаларны әзерләү һәм тарату эшендә Абдулла Алиш, Әхәт Атнашев, Зиннәт Хәсәнов актив катнашкан» [6]. «Озакка сузылган тикшерүләрдән соң Каршылык вәкилләре Дрезденда Империя суды каршына бастырыла. Аның карары нигезендә 1944 елның 12 февралендә 11 кеше үлем җәзасына хөкем ителә. Алар – Муса Җәлил, Гайнан Кормашев, Абдулла Алиш, Әхәт Атнашев, Абдулла Батталов, Фоат Булатов, Сәлим Бухаров, Фуат Сәйфелмөлеков, Зиннәт Хәсәнов, Гариф Шабаев. Барысының да хөкем карары текстында «дошманга ярдәм итү», «хәрби көчкә аяк чалу» кебек сәбәпләр күрсәтелә. Әлеге формулировка «Идел-Урал» легионында каршы тору яшерен оешмасы булганлыгын, аның эшчәнлеге «өченче рейх»ка каршы шактый зур зыян салуын дәлилли [6]. Татар патриотларының гильотинада башын чабып өзәргә дигән хөкем карары Берлинның Плётцензее төрмәсендә 1944 елның 25 августында гамәлгә ашырыла.

«Кайда минем илем?» спектаклен сәхнәләштерүчеләр капелла һәм культвзводның тормышын күз алдына бастыра. Әлеге әсәр «Идел-Урал» легионының гафу ителмәгән, онытылган герой-легионерларының тарихы буларак күзаллана. Сценарий авторы милли тарихтагы «ак тап»ларны бетерергә омтыла. Спектакльдә яшь артистлар Р. Йосыпов, И. Гыймалетдинова, А. Шаһимәрдәнов, Д. Хөснетдинов, Ф. Сафиуллин, Р. Әхмәдиев, А. Мифтахов, Э. Нургалиев катнаша. Спектакль дәвамында яңгыраган җырлар «Булат җыры» (К. Тинчурин сүз., С. Сәйдәшев көе), «Даниягә» (Г. Кормаш сүз., Ю. Чаплин көе), «Тәфтиләү» (Г. Тукай сүз., татар халык көе), «Урман кызы» (Һ. Такташ сүз., Җ. Фәйзи көе), «Сагыну» (М. Җәлил сүз., З. Хәбибуллин көе), «Ак каен» (З. Ярмәки сүз., М. Вәлиев көе) аша, бер яктан, безгә М. Җәлилнең замандашларының тавышын яңгыраталар, икенче яктан, фольклор һәм музыканың героик рух, Туган илгә мәхәббәт тәрбияләүдә әхлакый потенциалын ассызыклыйлар. Спектакльдә Муса Җәлил – (Альберт Шаһимәрдәнов) геройларча һәм иҗади рухта күзалланган эпизодик персонаж. Ул – фашистларга каршы торуны оештырган яшерен оешма вәкилләренең берсе. Аның образы капелла образы белән, ягъни иҗат дөньясы белән тыгыз бәйләнгән. Спектакльдә М. Җәлилнең халык җырларыннан һәм такмаклардан өзекләр җыеп, «Шүрәле» либреттосын иҗат итүе күрсәтелә. Г. Шәрәфетдинова билгеләп үткәнчә, әсәрнең эчтәлеге фашистларга каршы корылган була. Шул рәвешле, спектакльдә М. Җәлилнең шигъри осталыгы фольклорның сәнгатьчә чагылышы аша ачыла. Бер үк вакытта шагыйрь образы рухи җитәкче, лидер статусында да күрсәтелә. Әсәр эпизодында легион вәкилләренең Сөембикә мирасы турында сөйләшүләре аерым семантик мәгънәгә ия.

Белгәнебезчә, Сөембикә манарасы Татарстанда гына түгел, ә чит төбәкләрдә дә мәгълүм. Ул барлык татар халкы өчен Туган ил иминлеге, элекке дәүләтчелек символы булып тора. Манара диварындагы язманың мәгънәсен Муса Җәлил офицерга ватанпәрвәрлек хисләре белән бәйләп аңлата. Татар эмигрантлары өчен ул Идел-йорт символы, ә совет халкы өчен – Совет Татарстаны символы. Режиссер спектальдә М. Җәлил карашларының миллилигенә игътибар итә.

Герой-шагыйрь монда либретто остасы, татар фольклоры белгече буларак ачыла. Шагыйрь спектакльдә яшерен оешма вәкиле, тоткыннар арасында аңлату-тәрбия эшен алып баручы сәләтле агитатор буларак күрсәтелә.

Муса Җәлил иҗаты спектакльдә «Сагыну» (З. Хәбибуллин көе), «Двинада» («Эшче» операсындагы Нигъмәт ариясе мотивына) җырлары аша яктыртыла һәм төп идеяне ачарга ярдәм итә. Спектакльнең хронотобы музыкаль нигез аша киңрәк ачыла. Тамашачыларга 1920-1930 елларның музыкаль мирасы белән танышу мөмкинлеге тудырыла.

2023 елның 30 ноябрендә Әлмәт театры коллективы һәм чакырылган сәнгать эшлеклеләре Муса Җәлил һәм Нәҗип Җиһановның күренекле «Алтынчәч» операсына яңа ноктадан карау омтылышы ясый. Шуның нәтиҗәсендә ачык финал белән «Алтынчәч. Мирас» арт-хаус драмасы туа. Муса Җәлил

анда автобиографик каһарман дәрәҗәсендә сурәтләнә.

Персонажы – герой-шагыйрь Муса Җәлил чикләреннән чыкмый гына (Динар Хөснетдинов, ТРның атказанган артисты), режиссер аның аңындагы вербаль булмаган эчтәлекне вербаль чаралар аша ачуга ирешә. Шул ук вакытта Муса Җәлил татар милли опера сәнгатенең башлангыч чорында иҗат ителгән танылган опера либреттосы авторы буларак катнашса да, аның образы «күп белүче автор» хисеннән азат. Рухи яктан ирекле итеп тасвирланган герой безнең алда Шагыйрь-иҗатчы торганны аңларга ярдәм итә. Шул ук вакытта логик бәйләнешләр арткы планга күчерелгән. Теге яки бу мизансценаның интерпретациясе тамашачының әзерлек дәрәҗәсенә дә бәйле.

Арт-хаус драмада әдәби текстның ассоциатив мөмкинлеге чыганагы булып сүзнең эчке формасы тора. Ул үз эченә гасырлар дәвамында тышкы формада гына сакланып калган бер төркем ассоциацияләрне берләштерә һәм тел чаралары ярдәмендә ассоциацияләр рәте хасил итә. Спектакльнең исеме, бер яктан, безне танылган халык экиятенә һәм милли опера сәнгатенең башлангычына кире кайтара, икенче яктан, сәнгатьтә дәвамчанлык проблемасын калкытып куя. Киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм булганча, М. Җәлил либреттосын эшләгәндә, фольклор чыганакларына, үткәннәр мирасына («Җик Мәргән» героик эпосы, «Алтынчәч», «Туктар», «Алтын каурый» экиятләре һ.б.) таяна [14]. (Кара: Н. Юзиев). Мурат Абулкатинов спектаклендә «Алтынчәч» операсы шулай ук мәдәни мирас статусын ала. Төрле чыганакларда опера төрле исемнәргә ия. Беренче афишада М. Җәлил белән Н. Җиһановның уртак иҗат җимеше – «АЛТЫН ЧЕЧ», тамашачылар өчен программкада «Алтын чеч» дип аталган. Соңрак опера исеме ике вариантта очрый: «Алтынчеч», «Алтынчач». Муса Җәлил опера исеменә ни өчен вакыйгаларны үз тирәсенә җыеп торган Тугзак-ана исемен чыгармавын композиторга болай дип аңлата:

> «Алтынчәч матур яңгырый. Син бит музыкант! Син шуны аңламадыңмыни? Килешәм, Тугзак – фаҗигале образ. Ә без матурлык аша фаҗигагә килик» [15].

Поэтик исем эзләү барышында Муса Җәлил игътибарын экияти образны күрсәтү аша матурлыкны ачарга омтылуда чагыла. Шул юл белән милли күтәрелеш чорында иҗат кешеләре алдындагы бурычны билгеләп, дөньяга милли сәнгать казанышларын күрсәтүнең нигезләрен ассызыклый. Шуның өчен, безнең карашыбызча, беренче белдерүдә операның исеме «Алтын чач» дип күрсәтелгән була. Шул хәлендә ул «Алтын чәч!» дигән өндәмә булып яңгырый.

Шул ук вакытта опера «алтын чәч» атамасы белән тыгыз бәйләнгән. Чәчләр кеше гәүдәсенең өске өлешендә урнашу сәбәпле, рухи көчне чагылдыра. Шунысы мәгълүм, элекке заманнардан ук алтын чәчләр соляр символикага барып тоташа, ягъни кояш нурлары, кояш символикасы белән бәйле булганнар [16. б. 117].

«Алтынчәч» операсының тамашачылар тарафыннан югары дәрәҗәдәге иҗат җимеше буларак кабул ителүе очраклы хәл түгел. Аны иҗат итүчеләрнең төп казанышы сәнгати нигезне саклап калган хәлдә, милли мәдәниятне яңа баскычка күтәрү, шул ук вакытта милли аудиторияне саклап калу. Н. Җиһанов операсы гади халык вәкилләре тарафыннан «чит», «башка», «икенче» буларак түгел, «үзебезнеке» дип кабул ителде. Тиз арада аерым партияләр халык арасында мөстәкыйль әсәр булып та танылдылар. Моңа Гадел Кутуй истәлекләре дәлил булып тора. Аңа фронтта Алтынчәч ариясен «Әнкәй догасы» дип җырлаганны ишетергә туры килә [15]. Шундый югары бәяне әсәр премьерасы барган көннәрдә белгечләр дә раслый. Әйтик, композитор Альберт Леман хатирәләрендә «Алтынчәч»тә «камиллек өстенлек итә, милли йөрәкләргә якын, кадерле, гомумиләштерелгән югары эстетик зәвыклы, яшәеш нигезләренә якын образлар яши» дип язып калдырган [15].

Борынгы күзаллаулар буенча, Алтын чәч образы шулай ук бөҗра потенциалын (бер Асылның икелек гәүдәләнеше) да үз эченә ала. Монда капма-каршы башлангычларның берләшүе күзгә ташлана: актив һәм пассив, тартып торучы һәм читкә этәрүче, төзүче һәм җимерүче.

Спектакль сюжетының доминантасы булып фольклор традицияләре кысаларындагы ватанпәрвәрлек тора. Бу идеяне көчәйтү өчен режиссер белән драматург бөҗралы композициягә мөрәҗәгать итәләр. Каймалап алу чарасы буларак, И. Зәйниев М. Абдукатинов Нәкый Исәнбәт сүзләренә һәм халык көенә иҗат ителгән «Илкәем» (1917)

җырын файдаланалар [17]. Ул – гасыр дәвамында дөньяның төрле почмакларында яшәгән татарларның күңелен яулап алган җыр. Әсәр Туган илгә мәхәббәт манифесты булып яңгырап, геройның да мөнәсәбәтен чагылдыра. Н. Исәнбәт текстында Туган ил алдындагы бурыч һәм кешенең «Туган җирнең сандугачы» булуы белән тыгыз бәйләнә.

«Алтынчәч. Мирас» спектакленең төп өлешен аждаһа белән көрәш сюжетының яңа вариациясе тәшкил итә. Туган җирнең гармонияле яшәешенә куркыныч тудырган Аждаһа тираниясе белән очрашкач, халык яклаучылары, көрәш юлына басып, Герой, Ватанны саклаучы статусына ия булалар. Әлеге сюжет белән параллель рәвештә спектакльдә милли характерлар һәм дөньяның милли образлары контекстында шагыйрь һәм шигърият, халык һәм дәүләт кебек темалар күтәрелә.

«Алтынчәч. Мирас» спектаклендә кинематографиягә хас чалымнар да күзгә ташлана. Ул режиссерның ситуацияне динамикада күрсәтергә теләве, фрагментларны гадәти булмаган рәткә тезәргә, шулай ук укучы-тамашачының кабул итү процессын вакыт һәм пространствоны әле тегендә, әле монда күчерү юлы аша идарә итү ихтыяҗы белән аңлатыла (тулырак бу техника турында И. Мартьянов китабында) [18].

Муса Җәлил либреттосының әдәби текстын күзаллау барышында И. Зәйниев һәм М. Абдукатинов «авторның күзаллау тәҗрибәсен», укучыны һәм тамашачыны берләштереп, шулай ук әдәби җирлекне хәрәкәттә тасвирлап, күзаллау образларын берләштерү юлы белән «оптик метафора» тудыралар, шул юл белән укучы игътибарын предметка яки хәрәкәткә юнәлтеп, укучыга эмоциональ йогынты ясап, аларны бергәләп иҗат итүгә этәрәләр. Болгар ыруының акрынлап бетеп баруын сурәтләү (Хор трансформациясен кара), шул исәптән Янбулат (Рамазан Йосыпов), Каракаш (Диләрә Фазлиева) үлеме дә шуның белән аңлатыла.

Либреттоның шагыйрь-авторы карашынча, персонажларның берсеннән икенчесенә таба «шууын», предметларның берсеннән икенчесенә күчүе кебек таркау фрагментларның «берләшүен» күзәтү барышында тамашачы тулы бер чынбарлык картинасын тудыруның шаһитына әверелә. Шагыйрьнең авторлык карашы бер-бер артлы сөйләүче персонаждан икенчесенә, еш кына аларның репликаларын бүлә-бүлә дәвам итү рәвешендә күчеп бара.

Сәхнәдә хәрәкәтне тудыру өчен режиссер төрлечә планлаштыруга мөрәҗәгать итә: гомуми планнан төгәлгә күчү (Алтынчәч белән очрашу мизансценасын кара). Спектакльнең «күзәтү ситуациясен» эшләү барышында режиссер еш кына Шагыйрь һәм аның персонажларының карашларын тәңгәлләштерә. Хәтта Шагыйрь үз персонажына әверелеп, Алтынчәчне һәм аны эзәрлекләүчеләрне коткару очрагындагы кебек, опера сюжетына кереп китә. Кайбер очракта тамашачы яктылык һәм шәүлә йөреше аша (рәссам Софья Шнырева), аңа ишетелгән тавышлар аша (саунд-дизайнер Симон Маркевич) аңларга тиеш була.

Хәтта берни күренмәгән вакытта да, тавыш образларын тудырып, М. Абдукатинов укучы күзаллавын активлаштырып, аны иҗат эшенә кушылып китүенә ирешергә омтыла. Гомумхалык фаҗигасе сурәтен тудыру аша режиссер басып алучы Олуг-хан гаскәрләре (Чыңгызханга ишарә?) белән бәрелештә һәлак булган Тугзак-ана ыруы вәкилләре Хорына берничә тапкыр мөрәҗәгать итә. Хор партияләре пианистик техникага хас пластик хәрәкәтләрдән торган репликалар яки техник чаралар аша күрсәтелә (пластика буенча режиссер Никита Беляков). Шагыйрь персонажларының хәрәкәтен акрынайтып яки тизләтү аша иҗади максатына таба бара. Рәссам яктылык аша төрле визуаль тәңгәллекләр тудырып, төрле мәгънәләрне көчәйтүгә ирешә: Алтынчәчнең чәчләре әкренләп арткы нарат кәүсәләренә үрелә, сүзсез рояль – яңгырый торган язу өстәленә әверелә һ.б.

Спектакльнең төп герое итеп, Муса Җәлил күрсәтелә. Сурәтләү предметы – милли операның Мәскәүдә узачак Татар сәнгате декадасына әзерлек чорының иҗади акты. Динар Хөснетдиновның (ТР атказ. артисты) героеның карашы Мәңгелеккә омтылган. Тарих төтенендә ул милли тормыш серләрен табарга омтыла. Бу тенденция сценографиядә XX гасыр башы шагыйре Габдулла Тукайның иҗади табышы булган наратлар тасвирланган пәрдә рәвешендә арткы планда бирелә. Чагыштырыгыз: автобиографик герой туган ягының гимнына әверелгән «Шүрәле»дәге наратларга карап соклана, чиксез урманнарны дәһшәтле гаскәр белән чагыштыра: «Рәт-рәт тора, гаскәри кеби, чыршы, нарат» [19]. Милли идеал булган Батыр (Былтыр) феномены (Г.

Тукай, «Шүрәле» поэмасы) турында уйланып, спектакльдә шагыйрь тамашачылар күз алдында татар халкының үткәне белән бәйле хатирәләрне, шулай ук үз тормышының «серле йомгагын» сүтә («Серле йомгак», 1943) [20]. Акрынлап халык тарихында Шагыйрь Батыр статусын ала: 1956 елда Муса Җәлилгә үлгәннән соң Советлар Союзы герое исеме бирелә.

Рәссам Софья Шнырова ишекләрне һәм тәрәзәләрне халык тарихы порталлары сыман тасвирлый. Шуның аша Шагыйрь аңында берничә хронотоп яшәвенә басым ясый. Әкияти-мифологик хронотоп тарихи, биографик вакытның перциптив хронотобы белән тыгыз бәйләнә. Шул ук вакытта спектакльдә ыруның «балачагы» – болгар дәүләтен тудыру чоры – патриархаль идиллия статусын ала, Алтын чорга куркыныч янаган тиран − Аждаһа Олуг-хан (Мәмәт хан) Шагыйрьгә капма-каршылыкта ачыла. Аждаһага охшаш сюжет тудыру вакытында спектакль авторлары шкафтан татар халкының “скелет”ларын тартып чыгаралар, шуның аша әһәмиятле метафоралар тудыралар. Тарихи истәлекләрне сурәтләү бәрабәренә спектальдә сурәтләнгән Аждаһа төрле кыяфәтләргә керә. Шагыйрьнең иҗади карашларында берничә тарихи тәңгәллек тууы күрсәтелә: Урда башында торган Олуг-ханның һөҗүме нәтиҗәсендә Болгар дәүләтенең җимерелүе, Сталин репрессиясе (1920–1950) нәтиҗәсендә Советлар дәүләте таркалу, Гитлер җитәкчелегендә фашистларның бәреп керүе. Стенографиядә Чехов стилендә тасвирланган китап шкафы традицияләрнең мәңгелеген символлаштыра.

Язу өстәле Муса Җәлилнең шәхесе буларак күзаллана. Ул спектакльдә Иҗатчының халык күңелен тибрәтә торган коралга әверелә. *Радио* һәм *көймәнең* антитезасы романтик төс ала: поэтик хыялның һәм кырыс чынбарлыкның антитезасына әверелә. Шул ук вакытта көймә образы кызыксынучан тамашачы өчен Дәрдемәнднең «Кораб» шигырендәге «Ил корабын җил сөрә!» юлларында язылганча, усал җилнең җилкәнне ертуын тасвирлау аша хрестоматик кораб образы искә төшерелә [21, б. 27].

Спектакль дәвамында Шагыйрьнең «халык сандугачы»на әверелүен, халык күңелендә яңгыраган кайтавазны ишеткәндәй булалар. Сюжетның опера өлеше хор партияләре һәм рояль образы белән тулыландырыла.

Шагыйрьнең игътибар үзәгенә татар халкының данлы үткәнен генә түгел, ә хәзерге фаҗигале хәлләр дә куела. Хронотоп Муса Җәлил замандашларының тормыш вакыйгаларын кертү исәбенә дә киңәйтелә. 1920–1930 елларда Шагыйрьгә җәдитчелек һәм милли идеяләр үзгәрешенең шаһиты булырга туры килә. Моңа опера мизансценаларын К. Тинчуринның һәм С. Сәйдәшевның «Зәңгәр шәл» (1926) музыкаль драмасындагы Булат ариясе белән бүленүе дә ишарә ясый. Бу спектакль 19 еллык тыюдан соң 1957 елда гына сәхнәгә кайта, ә аның бер авторы 1937 елда атып үтерелә. К. Тинчурин татар театрының һәм милли драматургиянең алтын фондын тәшкил иткән музыкаль драмалар, комедияләр тудыручы автор буларак халык хәтерендә мәңгелек урын яулый.

Сталин раепрессияләренең тагын бер вәкиле булган Хәсән Туфан – Муса Җәлилнең чордашы буларак күрсәтелә. Кадакланган тоткын образында Айрат Мифтахов шагыйрьнең «Илдә ниләр бар икән?» (1944) дигән атаклы шигырен укый. Бу шигырь данлыклы август Карары яктысында «Алтын Урда»ны тар-мар итү елы истәлегенә язылган. Әлеге документны кабул итү, тарихчы А.Г. Галләмова сүзләренә караганда, «милли рухи хәзинәнең күтәрелеш этабын йомгаклауда борылыш чорын чагылдырган 1930 еллар ахырын күрсәтә» [19]. Бер яктан, татар интеллигенциясе корбан дәрәҗәсендә калса, икенче яктан, 1950–1980 елларда этногенетик югалтулар шартларында «социо-, морфо-, формогенез күзлегеннән» казанышларын яктырта [22].

Сәхнә әсәре авторлары Шагыйрьнең замандашлары мохитендә генә түгел, ә татар әдәбиятының мәңгелек образлары галереясендә дә тарихи тәңгәллекләр үткәрә. Шул рәвешле, эпос герое Җик-Мәргән XX гасыр башында Г. Тукай иҗатында үзенең кыюлыгы белән Шүрәледән дә өстенрәк Батыр-Былтыр итеп күрсәтелгән. 1920–1930 елларда аңа алмашка бәхет эзләп, чит җирләрдә йөреп, гаилә кору максаты белән Туган иленә кайткан, көндәшенең корбанына әверелгән танылган музыкаль драма герое Булат килә. Булатны яңа геройлар – Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Муса Җәлил алмаштыра.

А. Г. Галләмова ачыклавынча, алар дәүләт карарларына каршы үзенчәлекле иммунитет булдырган, карашлары мәдрәсә шартларында, бердәм тоталитар басымга кадәр формалашкан

«татар иҗади элитасы вәкилләре». Алар Марк Захаровның «Аждаһаны үтерергә» фильмындагы беренче укучылары шикелле, гайрәтле аждаһа системасының мәгънәсез шартларына каршы торырга омтыла. Гуманитар юнәлештәгеләр арасында «аждаһалык»ка каршы торучы, татар халкы хакына «үз җирен» яклап, аның идеологик тамгаларга каршы торучы Ланцелотлары да булган [21. б. 787].

Артистларның сәхнәдә үз-үзләрен тотышлары алар башкара торган персонаж роленең хронотоптагы характерына бәйле. Спектакльдә опера эпик геройларының тотрыклы тасвиры шуның белән бәйле: фольклор хронотобында кеше образының тышкы кыяфәтен үзгәртмичә, тотрыклы итеп, шәхси сыйфатларын калку тасвирлау аша ачыла. Муса Җәлилнең әдәби образының автобиографик хронотобы аны граждан буларак күзалларга ярдәм итә. Чынбарлыктагы биографик вакыт тулысынча диярлек идеаль һәм абстракт вакыт метаморфозалары эчендә тулысынча таркала. Күрсәтелгән хронотопта тарихи инверсия барлыкка килә, ул вакытта сәнгатьчә фикерләү татар халкының беренче дәүләтчелеген төзүгә бәйле булган Алтын гасыр турындагы мифта максат, идеал, гаделлек кебек категорияләр аша күзаллана.

Фольклор сюжетларын чишә-чишә, Шагыйрь Тугзак-ана – ыру анасы дигән архетипны яңадан тудыра. Спектакль-ремейкта «Идегәй»дәге Субра карт кебек ул мәңгелек образ дәрәҗәсенә күтәрелә. Тугзак-ана үзенең улларын ыру тарихы белән таныштыра, үзенең киңәш-күрсәтмәләрен бирә, аларга Җик-Мәргәннең киемнәрен кигертеп карап, Туган ил сакчысы буларак, сакраль миссиягә – батырлык эшләргә әзерли. Мәдинә Гайнуллина үзенең персонажын тудыру барышында читләшү алымына таяна. Дидактик якның көчле булуына да карамастан, Тугзак-ана образы психологизмнан читләштерелгән. Ул үзенең кыйммәтле киңәшләрен батыр оныгына бирү өчен бер вакыт чигеннән икенчесенә җиңел генә күчә. Әлеге персонажның киемнәре борынгы трагедия геройлары стилендә күрәзәче-картларныкы кебек тегелгән.

Муса Җәлил замандашларының тавышын тудыру барышында И. Зәйниев интертекст мөмкинлекләрен файдалана. Драматург ватанпәрвәрлек феномены турында уйланганда, әдипнең Әминәгә язган хушлашу хаты текстын һәм операдагы Тугзак-ананың киңәшләрен берләштерә:

«Я заповедь одну скажу вам, дети,
Ее вы помните и впредь:
Чем на коленях жить на свете,
Достойней стоя умереть!» [13].

Шагыйрь турындагы әсәрнең композициясе булып аның язу өстәленнән һәм үзенең геройларыннан аерылып, күтәрелеп китүе тора. Шагыйрь үзенең батырлыгы, «Моабит дәфтәрләре» шигырьләр циклы аркасында халык хәтерендә җуелмас эз ала.

Спектакльне куючылар шагыйрь һәм тамашачы арасын якынайту өчен аны автобиографик хронотоп чикләрендә сакчыл ата буларак та ачалар. Бу теманы ачу барышында И. Зәйниев тамашачыны тапталган сукмактан читләштереп (кызы Чулпан темасы), озак еллар дәвамында иҗтимагый игътибардан читтә калып килгән беренче баласы туу тарихына юнәлтә. Шагыйрьнең олы улы Альберт Җәлилов ил сакчысы юлын сайлый. Ул Саратов химик саклау хәрби-инженер училищесын тәмамлап, Совет Армиясендәге хезмәтен подполковник дәрәҗәсендә тәмамлый. Альберт Җәлилов үзенең әтисе белән горурлана, аның биографиясен өйрәнә, шигырьләрен яттан укый.

Шагыйрь образын эшкәртү барышында күпмәгънәле кош образына аерым игътибар бирелә. Ул башта персонаж кулында кәгазь кош формасында була. Бу образ тамашачы игътибарын «Илкәем» җырындагы каймалап алу алымына юнәлтә (чаг. сандугач). Хор тарафыннан башкарылган (Лилия Заһидуллина, Алсу Сибгатуллина, Миләүшә Юзаева, Энҗе Сәйфетдинова, Илүзә Нәбиуллина) бишек җыры белән кушылып, метафорачыл мәгънә ала: бала – ыру оясындагы кош, киләчәк символы. Икенче яктан, кәгазь кош батырлык мөмкинлеге, персонажның тагын да югарырак баскычка күтәрелүе белән бәйләнгән. Спектакльдә өч тылсымлы каләм искә алына: Җик-Мәргән тарафыннан торнадан атып төшерелгән каурый – себер татарларының тотемы. М. Җәлил операсында торна тылсымлы ярдәмче, саклау чарасына әйләнгән каурый тотем статусы ала.

Шул ук вакытта герой-шагыйрьнең улы биографиясенә дә игътибар юнәлтә. Шунысы билгеле, Альберт Җәлилов очучы булырга хыяллана, әмма балачакта алган җәрәхәтләре бу хыялны тормышка ашырырга комачаулый.

Менә шуның өчен Муса-ата бишек җыры яңгыраганда улына канатлы кош уенчыгы ясый һәм аңа Җик-Мәргән киемен кидертә. Соңыннан төш чынбарлыкка әйләнеп, саташу рәвешендә ата үзенең улын югалта. Шагыйрь кулында Батырның киемнәре һәм авыр китап томнары гына кала – алар иҗади үлемсезлеккә ишарә ясый.

Шагыйрьнең фаҗигале язмышы Динар Хөснетдинов тарафыннан пластик хәрәкәтләр аша күрсәтелә. Геройның тормыш драмасы, үтеп баручы тормышның авыр борчулары либреттоның тиз укылышындагы өзектә психологик яктан дөрес күрсәтелгән.

Герой-шагыйрь тормышыннан фронт этабын визуальләштергәндә, аны фаҗигале герой буларак тасвирлыйлар. Спектакльдә кеше һәм аның яшәешенә куркыныч тудырган тимер кош антитезасы мөһим әһәмияткә ия.

Тугзак-ана Шагыйрьне Сталин репрессиясеннән сакларга омтыла: ул Пандора тартмасы кебек булган шкафны каты итеп яба. Тузгак ана сугыш вакытында коты алынган шагыйрьне тынычландырырга тырыша. .Нәкъ Тугзак-ананың каршылыклардан чыгу юлын күрсәткән кәгазь тоттыруы символик яңгырашка ия.

Спектакль ахырында Шагыйрь Тукай тарих пәрдәсе җирлегенә күченә. Пыяла артында геройны киендерү күренеше үлеменнән соң язучы мифы кичергән үзгәрешләрне тасвирлый. Шунысы мәгълүм, шагыйрьнең рәсми рәвештә исеме акланганчы, опера театр афишаларыннан югалып тора.

Финал өлешендә шагыйрь образы тамашачыларны ирек һәм тоткын темасына кайтара. Хушлашу вакытында Муса Җәлил «Ялгыз учак» шигырен укып, үзен томан эчендә йөрүче кораб белән чагыштыра, ул кабызган учакны күрүчеләр, саклаучылар булыр дигән өмет баглый.

Каракош (Диләрә Фәизова) һәм Алтынчәч (Ләйсән Заһидуллина) образларында корбан булу алгы планга чыга. Тугзак-ана фонында алар пассив персонаж буларак күренә. И. Зәйниев бу образлар өстендш эшләгәндә әкияти-мифологик традицияләргә таяна, шуңа күрә бу геройлар аждаһа-коткаручы йогынтысына бәйле итеп күрсәтелә.

Спектакльдә музей җыештыручысының образы ачылмаган. Чынбарлыктагы образ булуына карамастан, ул гротеск белән тулыландырылган. Бер яктан, кара халат кигән фигура тамашачыны тынычландыра, икенче яктан, куркыныч тудыра. Муса Җәлил операсыннан аермалы буларак, И. Зәйниев һәм М. Абукатинов үзенең тамашачыларын арт-хаус драмасына хас булганча, билгесезлеккә ата. Спектакль тудыручылар татар мәдәниятенең музейларда һәм китапларда гына сакланып калуын һәм аларга халык кулы җитмәсен күреп борчыла. Шуның ачык дәлиле итеп, музей җыештыручының шагыйрьнең хатын гына укып, аның кульязмаларын, китапларын күрмәвенә басым ясыйлар.

Спектакль музыкаль яктан да үзенчәлеккә ия. Операның үткәне хор, музыкаль партияләрдә чагылыш таба. Шагыйрьнең иҗади фикерләү сәләтен күрсәтү өчен саунд-дизайнер тамашачыларда төрле ассоциацияләр тудыра торган кызыклы авазлар уйлап таба.

Сәхнә әсәре өстендә эшләү барышында режиссер М. Абукатинов, безнең карашча, милли мәдәнияне текст, миф, ментальлек аша күрсәтүне киң колачлы итеп ачуга ирешкән. Нәтиҗәдә модернистик әсәр – әдәби нигездән ерак торган, «аң агышын» күрсәткән текст хасил булган. Драматург И. Зәйниев белән берлектә эшләү нәтиҗәсендә фольклорны заманча күзаллауга, төгәлрәк әйтсәк, аллюзияләр белән тулыландырылган мифологик сюжетлы үткән белән бүгенгене бергә үргән образлар һәм текстлар туган.

**Нәтиҗәләр**

Шагыйрь мифын булдыру өчен шагыйрь образын мәдәниятебездә күптән расланган матрицаларга туры китерергә кирәк. Без «Кайда минем илем?» һәм «Алтынчәч. Мирас» спектакльләре аша шагыйрь турында мифның яңа мәгънәви юллары үстерелүен күрәбез: шагыйрь һәм һәйкәл (мәдәнияттә үлемсезлек), шагыйрь һәм халык; шагыйрь һәм хакимият; шагыйрь һәм үлем; шагыйрь һәм шәһит; шагыйрь һәм муза; шагыйрь һәм Туган ил. Шул ук вакытта икенче тенденция дә үзен сиздерә: "мифобежная" яки мифтан качу. Спектакль тудыручылар «һәйкел» артында кешене күрергә, аның карашларын аңларга, язмышын күзәтергә, иҗатының үлемсезлеген, батырлык чыганакларын аңларга омтыла. Әлмәт сәхнәсендә туган Шагыйрь мифы Радик Кудояровның «Кара урман» фильмында тасвирлаган мифыннан күпкә уңышлырак (бу хакта М. Хәбетдинова рецензиясен карагыз [24]).

**Әдәбият**

1. Библиографический справочник «Муса Джалиль» // URL: https://kitaphane.tatarstan.ru/jal.htm?ysclid=mdfj5zkei51649071 (мөрәҗәгать итү вакыты 02.02.2024)
2. *Хәбетдинова М. М.* Нинди рәхәт, кешең булгач үрнәк алырга / М.М. Хәбетдинова // Ялкын. 2019. №2. Б.34–35.
3. *Закирҗанов А.* «Кайда минем илем?» // URL: https://sahne.ru/news/zhurnalda-ukygyz/kayda-minem-ilem(мөрәҗәгать итү вакыты 02.02.2024)
4. *Хабутдинова М. М.* «Муса. Моабит» (Триптих). // Звезда Поволжья. 2021. 15-20 мая. №18 (1032). С. 4.
5. *Юхновкая О.* Свой выпускной экзамен 80-летняя Казанская консерватория сдала на отлично // Вечерняя Казань. 2025. 9 июня. // URL: https://www.evening-kazan.ru/kultura/articles/svoy-vypusknoy-ekzamen-80-letnyaya-kazanskaya-konservatoriya-sdala-na-otlichno?ysclid=mdl8rigvyn689830026&utm_source=yandex.ru&utm_medium=organic&utm_campaign=yandex.ru&utm_referrer=yandex.ru (мөрәҗәгать итү вакыты 02.07.2025)
6. *Гилязов И. А.* Восточная политика Германии и легион «Идель-Урал». Бессмертный подвиг Мусы Джалиля // Виртуальный музей Великой Отечественной войны // URL: https://tatfrontu.ru/content/vostochnaya-politika-germanii-i-legion-idel-ural-bessmertnyy-podvig-musy-dzhalilya?ysclid=mdlb9n9ijq591507884(мөрәҗәгать итү вакыты 02.02.2024)
7. *Забиров И. Х.* Джалиль и джалильцы: Докум. очерки и этюды. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 140 с.
8. *Мустафин Р.А.* По следам поэта-героя: Книга-поиск: [О М. Джалиле]: Москва: Дет. лит., 1971. 271 с.
9. *Ахтамзян А.* О «Курмашеве и десяти других», казненных в Берлине за «подрыв военной мощи» Германского рейха // Татарские новости. 2002. № 1(90).
10. *Черепанов М.* Служили примером для французских партизан // Виртуальный музей Великой Отечественной войны // URL: https://tatfrontu.ru/news/sluzhili-primerom-dlya-francuzskih-partizan?ysclid=mdmluk82pw127228268/ (мөрәҗәгать итү вакыты 02.02.2024)
11. *Гыйләҗев А.* Сайланма әсәрләр : 6 т. – 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 743 б.
12. *Фәхретдинов Г.* Кайда минем илем? // Казан утлары. 1994 №8. С. 136–151.
13. Алтынчач: опера Назиба Җиганова в 4 действиях, 6 картинах; либретто Мусы Джалиля // URL: https://www.belcanto.ru/opera_altynchach.html?ysclid=mdjp86bdzw677197974. (мөрәҗәгать итү вакыты 02.02.2024)
14. *Юзиев Н. М.* Җәлилнең иҗат лабораториясеннән // Совет әдәбияты. 1957. №6. С. 97–105.
15. *Агеева Л.* «Алтынчеч» – одна из лучших опер Назиба Жиганова // Казанские истории. 2011. 11 июля. // URL: https://history-kazan.ru/kazan-vchera-segodnya-zavtra/retrospektiva/6257-917?ysclid=mdjooezdd1278512267. (мөрәҗәгать итү вакыты 02.02.2024)
16. *Шахова Л. Н.* Солнечная символика в сказах П. Бажова // Дергачевские чтения – 96. Русская литература: национальное развитие и региональные особенности : тезисы докладов и сообщений научной конференции, Екатеринбург, 23–24 мая 1996 г. Екатеринбург : Издательство Уральского университета, 1996. С. 115–117.
17. *Исәнбәт Н.* Туган ил : [шигырь] // Балалар дөньясы. 1917. № 1 (март). 1 б.
18. *Мартьянова И.* Киновек русского текста: парадокс литературной кинематогра фичности. – СПб., 2002. – 236 с.
19. Тукай дөньясы: ижат // URL: http://gabdullatukay.ru/(мөрәҗәгать итү вакыты 02.02.2024)
20. *Джалиль М.* Волшебный клубок // Хабутдинова М. М. Навстречу бессмертию... [К столетию со дня рождения татарского поэта-антифашиста Мусы Джалиля.] Н. Новгород: Изд. дом «Медина», 2006. С. 41–42.
21. *Дәрдемәнд* Агарган кыл. Казан: Мәгариф, 1999. 112 б.
22. *Галлямова А. Г.* «“Расправа” над Золотой Ордой» в середине XX в.: Идеологический дискурс в татарской медиевистике в свете августовского Постановления 1944 г. // Золотоордынское обозрение. 2019. Т. 7, № 4. С. 784–797. DOI: 10.22378/2313-6197.2019-7-4.784-797/
23. *Галлямова А. Г.* Идеология и культура // Татарская АССР в период постстали низма. Казань, 2015. С. 325–445.
24. *Хабутдинова М. М.* «У совести вариантов нет» (Т.Миннуллин): [фильм «Караурман»] // Звезда Поволжья. 2025. №33(1235). 13-19 сентября. С. 1–2.

# ОБРАЗ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ НА СЦЕНЕ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО ТЕАТРА

**Милеуша Мухаметзяновна Хабутдинова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
mileuscha@mail.ru.

**Альфия Рухулловна Мотигуллина**,
Казанский государственный институт культуры,
Россия, 420059, г. Казань, ул. Оренбургский тракт, д. 3,
alfiya311065@mail.ru.

В статье анализируется образ Мусы Джалиля в спектаклях Альметьевского татарского государственного драматического театра «Кайда минем илем?» (2020, «Где моя Родина?», авт. Гараф Фахрутдинов, реж. Ильяс Гареев) и «Алтынчәч. Мирас» (2023, авт. Муса Джалиль, Ильгиз Зайниев, реж. Мурат Абдукатинов). Если первый из них создан на основе художественно-документальной прозы Г. Фахрутдинова, то второй является драмой-ремейком легендарной оперы Н. Җиганова и М. Джалиля «Алтынчәч» («Златовласка»). В спектакле И. Гареева Муса Джалиль фигурирует в качестве эпизодического персонажа поэта-подпольщика. Голос писателя оживает в песнях на его стихи, звучащих во время спектакля. В драме-ремейке М. Абдукатинова Муса Джалиль является главным героем. Новаторство режиссера проявилось в ассоциативном подходе в разработке его образа.

**Ключевые слова:** татарская литература, татарский театр, Муса Джалиль, миф о поэте, Ильяс Гареев, Мурат Абдукатинов

**Для цитирования**: Хабутдинова М. М., Мотигуллина А. Р. Образ Мусы Джалиля на сцене Альметьевского театра // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 110–127. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-110-127